КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 17 декабрь г.Казань № 1247

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасында санитария-эпидемиология хәлен һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу үзенчәлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 28 октябрь, 1006 нчы; 2021 ел, 29 октябрь, 1018 нче; 2021 ел, 17 ноябрь, 1100 нче; 2021 ел, 24 ноябрь, 1117 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның өченче абзацында «букмекер конторалары,» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2021 елның 30 октябреннән 23 сәгать 00 минуттан 6 сәгать 00 минутка кадәр (ә 2021 елның 20 декабреннән 2022 елның 10 гыйнварына (10 гыйнварны кертеп) кадәр 1 сәгать 00 минуттан 6 сәгать 00 минутка кадәр) иҗтимагый туклану хезмәтләре күрсәтүне (гражданнарга җәмәгать туклануы объектлары урыннарына керүне рөхсәт итмичә, алып чыгып бирү хезмәте күрсәтүдән, заказларны илтеп бирүдән, аэропортлар, вокзаллар территорияләрендә, торак пунктлардан читтә урнашкан юл

сервисы объектларында, федераль, төбәк һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында җылыту һәм туклану пунктлары булган җәмәгать туклануы объектларында җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтүдән тыш). Әлеге чикләүләр 2022 елның 1 гыйнварында 1 сәгать 00 минуттан 3 сәгать 00 минутка кадәр иҗтимагый туклану хезмәтләре күрсәтүгә кагылмый;»;

уникенче абзацта «җәмәгать туклануы объектлары урыннарында» сүзләреннән соң «, букмекер контораларында» сүзләрен өстәргә;

6 пунктка түбәндәге эчтәлекле «ж[1]» пунктчасын өстәргә:

«ж[1]) 2021 елның 20 декабреннән балалар өчен яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралу шартларында профилактик чараларның үтәлешен тәэмин итә торган формада Яңа елга багышлганган тамаша-күңел ачу чараларын үткәрүне. Шул ук вакытта 18 яшьтән өлкәнрәк тамашачыларга QR-кодларын күрсәтеп кенә керергә һәм булырга рөхсәт ителә;»;

әлеге карарга теркәлгән 1 нче кушымтаның 2 пунктындагы 2 пунктчасының икенче абзацында «җәмәгать туклануы объектлары урыннарында» сүзләреннән соң «, букмекер контораларында» сүзләрен өстәргә, «мәдәни чараларга» сүзләреннән соң «, балалар өчен Яңа елга багышланган тамаша-күңел ачу чараларына» сүзләрен өстәргә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин